МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14 ноября 2014 года № 374-ОД

г.Казань

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләүне коррупция куркынычы белән бәйле вазыйфалары исемлеген раслау турында**

2008 елның 25 декабрендәге "Ришвәтчелеккә каршы көрәш" 273–ФЗ номерлы Федераль Закон, 2010 елның 30 сентябрендәге ""Ришвәтчелеккә каршы көрәш" Федераль Законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар турында" УП–636 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә

боерам:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләүне коррупция куркынычы белән бәйле вазыйфалар исемлеген расларга (алга таба – Исемлек), вазыйфаи бурычларын үтәү түбәндәгедән гыйбарәт:

даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр нигезендәхакимият вәкиле функцияләрен яисә оештыру-боеру яки административ-хуҗалык функцияләрен башкару;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлеп бирү турындагы карарлар әзерләү һәм кабул итү, шулай ук чикле ресурсларны бүлеп бирү;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын гамәлгә ашыру;

материаль-техник ресурсларны саклау һәм бүлеп бирү.

2. Туплау бүлегенә (Минһаҗева Н.Н.) Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында "Коррупциягә каршы көрәш" бүлекчәсендә урнаштырырга;

3. Кадрлар бүлегенә (Сафина Д.М.) әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән граждан хезмәткәрләренә ирештерергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны министрның урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөкләргә.

Премьер-министр урынбасары – министр Р.Х. Зарипов

ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы
боерыгы белән расланган
«14» 11 2014 ел № 374-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләүне
коррупция куркынычы белән бәйле вазыйфалары исемле

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының югары вазыйфалар төркеме "җитәкчеләр":

министрның беренче урынбасары;

министр урынбасары;

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы вазыйфалар төркеме "ярдәмчеләр":

министр ярдәмчесе;

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының төп вазыйфалар төркеме "җитәкчеләр":

эшләр идарәчесе

энергетика идарәсе җитәкчесе;

юридик бүлеге мөдире;

финанс яктан планлаштыру, исәпләү һәм хисап бүлеге мөдире;

кадрлар бүлеге мөдире;

мобилизация эше бүлеге мөдире;

халыкара багланышлар бүлеге мөдире;

рәсми беркетмә бүлеге мөдире

тәрҗемә бүлеге мөдире

нефть һәм газ химиясе комплексын үстерү һәм программалаштыру бүлеге мөдире

нефть чыгару һәм эшкәртү бүлеге мөдире

химия һәм газ химиясе бүлеге мөдире

Машина төзелеше комплексы бүлеге мөдире

Оборона комплексы бүлеге мөдире

Сәнәгать инновацияләре һәм инвестицияләре бүлеге мөдире

Күргәзмә эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру бүлеге мөдире

Төбәкара багланышларны үстерү бүлеге мөдире

Кулланучылар базарын бүлеге мөдире

Агач эшкәртү һәм җиңел промышленность бүлеге мөдире

Туплау бүлеге мөдире

Анализлау бүлеге мөдире

Корпоратив идарә бүлеге мөдире

Оештыру эшләре бүлеге мөдире

Эш башкару һәм контроль тикшерү бүлеге мөдире

Дәүләт заказы секторы мөдире

Гомуми бүлек мөдире

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы вазыйфалар төркеме "җитәкчеләр":

халыкара багланышлар бүлеге мөдире урынбасары;

оборона комплексы бүлеге мөдире урынбасары;

анализлау бүлеге мөдире урынбасары;

корпоратив идарә бүлеге мөдире;

мәгълүмати технологияләр секторы мөдире;

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы вазыйфалар төркеме “белгечләр”:

энергетика идарәсенең электр энергетикасы бүлеге мөдире;

энергетика идарәсенең энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге бүлеге мөдире;

энергетика идарәсенең ягулык инфраструктурасы һәм газ белән тәэмин итү бүлеге.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы вазыйфалар төркеме “тәэмин итүче белгечләр”:

кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече (коррупцион һәм башка хокук бозу очракларын профилактикалау эше өчен җаваплы зат).